КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 397

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Мелиорация эшләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Мелиорация техникасын сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Балык үрчетү хуҗалыклары тарафыннан мәрсин балыгы төрләренең товар балыгын һәм товар уылдыгын сатуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен;

Сөт юнәлешендәге нәселле таналар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларының, әзерләү оешмалары һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында ит, йон һәм күн чималын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Кулланучылар кооперациясе оешмаларына күчмә сәүдәне гамәлгә ашыру өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Җитештерү егәрлекләрен модернизацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Төзелә торган сөтчелек комплексларын техника һәм җиһаз белән тәэмин итүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең аграр юнәлештәге квалификацияле белгечләр әзерләүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материаллары чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Сөт комплекслары төзелешенә проект-смета документациясен проектлауга һәм аларга дәүләт экспертизасын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Җиләк-җимеш культураларын үстерү өчен модульле теплицалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарындагы 1 пунктының икенче – дүртенче, җиденче – тугызынчы, унбишенче – унҗиденче, егерме беренче, егерме өченче, егерме сигезенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин